**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О преобразовании Министерства информатизации и связи Республики Татарстан

В целях обеспечения цифрового развития государственного управления в Республике Татарстан, в соответствии со статьей 94 Конституции Республики Татарстан, Законом Республики Татарстан от 6 апреля 2005 года № 64-ЗРТ «Об исполнительных органах государственной власти Республики Татарстан» **постановляю**:

1. Преобразовать Министерство информатизации и связи Республики Татарстан в Министерство цифрового развития государственного управления, информационных технологий и связи Республики Татарстан, передав ему от Министерства экономики Республики Татарстан функцию по развитию сети многофункциональных центров предоставления государственных и муниципальных услуг.

2. Установить, что Министерство цифрового развития государственного управления, информационных технологий и связи Республики Татарстан является правопреемником Министерства информатизации и связи Республики Татарстан, в том числе по обязательствам, вытекающим из заключенных соглашений и договоров.

3. Кабинету Министров Республики Татарстан:

обеспечить проведение реорганизационных мероприятий в соответствии с настоящим Указом;

разработать и утвердить положение о Министерстве цифрового развития государственного управления, информационных технологий и связи Республики Татарстан (далее – Министерство), предусмотрев в нем возложение на Министерство функции по обеспечению цифровизации в сферах государственного управления и оказания государственных услуг;

утвердить структуру и предельную численность работников Министерства;

определить размер ассигнований на финансирование деятельности Министерства, а также Министерства экономики Республики Татарстан с учетом передачи функции, предусмотренной пунктом 1 настоящего Указа, в пределах средств, предусмотренных в Законе Республики Татарстан

от 21 ноября 2018 года № 88-ЗРТ «О бюджете Республики Татарстан на 2019 год и на плановый период 2020 и 2021 годов»;

обеспечить в соответствии с законодательством предоставление гарантий и компенсаций государственным гражданским служащим Республики Татарстан и иным работникам в случае их высвобождения вследствие реорганизационных мероприятий, предусмотренных настоящим Указом;

привести свои акты в соответствие с настоящим Указом, а также принять иные решения, обеспечивающие его реализацию;

внести предложения по приведению актов Президента Республики Татарстан в соответствие с настоящим Указом.

4. Внести изменение в раздел II структуры исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан, утвержденной Указом Президента Республики Татарстан от 25 сентября 2015 года № УП-899 «О структуре исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 31 мая 2016 года № УП-491, от 2 августа 2017 года № УП-662, от 6 октября 2017 года № УП-890, от 26 декабря 2017 года № УП-1168, от 14 июня 2018 года № УП-426, от 22 июня 2018 года № УП-454 и от 28 июня 2018 года № УП-462), заменив слова «Министерство информатизации и связи Республики Татарстан» словами «Министерство цифрового развития государственного управления, информационных технологий и связи Республики Татарстан».

5. Внести изменение в перечень должностных лиц, входящих в состав Кабинета Министров Республики Татарстан – Правительства Республики Татарстан, утвержденный Указом Президента Республики Татарстан от 25 сентября 2015 года № УП-900 «О перечне должностных лиц, входящих в состав Кабинета Министров Республики Татарстан – Правительства Республики Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 22 ноября 2015 года № УП-1122, от 31 мая 2016 года № УП-491, от 29 августа 2017 года № УП-773, от 6 октября 2017 года № УП-890, от 20 февраля 2018 года № УП-187, от 22 июня 2018 года № УП-454 и от 5 июня 2019 года № УП-309), заменив слова «Министр информатизации и связи Республики Татарстан» словами «Министр цифрового развития государственного управления, информационных технологий и связи Республики Татарстан».

6. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
25 сентября 2019 года
№ УП-574

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгын үзгәртеп кору турында**

Татарстан Республикасында дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерүне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Конституциясенең 94 статьясы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгын, аңа Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре челтәрен үстерү вәкаләтләрен тапшырып, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы итеп үзгәртеп корырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының, шул исәптән төзелгән килешүләрдән һәм шартнамәләрдән килеп чыккан йөкләмәләр буенча да, хокукый дәвамчысы булып тора дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

әлеге Указ нигезендә үзгәртеп кору чараларын уздыруны тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы (алга таба – Министрлык) турындагы нигезләмәне, анда дәүләт идарәсе һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтү өлкәсендә цифрлы технологияләрне куллануны тәэмин итү функциясен Министрлыкка йөкләүне күздә тотып, эшләргә һәм расларга;

Министрлыкның структурасын һәм хезмәткәрләренең чик санын расларга;

Министрлыкның, шулай ук, әлеге Указның 1 пунктында каралган функцияне тапшыруны исәпкә алып, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының эшчәнлеген финанслауга ассигнованиеләр күләмен «2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2018 елның 21 ноябрендәге 88-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган акча кысаларында билгеләргә;

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм башка хезмәткәрләргә, алар әлеге Указда каралган үзгәртеп кору чаралары нәтиҗәсендә эштән җибәрелгән очракта, гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне законнар нигезендә тәэмин итәргә;

үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә;

Татарстан Республикасы Президенты актларын әлеге Указга туры китерү буенча тәкъдимнәр кертергә.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары структурасы турында» 2015 елның 25 сентябрендәге ПУ-899 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 31 маендагы ПУ-491 номерлы, 2017 елның 2 августындагы ПУ-662 номерлы, 2017 елның 6 октябрендәге ПУ-890 номерлы, 2017 елның 26 декабрендәге ПУ-1168 номерлы, 2018 елның 14 июнендәге ПУ-426 номерлы, 2018 елның 22 июнендәге ПУ-454 номерлы һәм 2018 елның 28 июнендәге ПУ-462 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары структурасының II кисәгенә, «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

5. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте составына керүче вазыйфаи затлар исемлеге турында» 2015 елның 25 сентябрендәге ПУ-900 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 22 ноябрендәге ПУ-1122 номерлы, 2016 елның 31 маендагы ПУ-491 номерлы, 2017 елның 29 августындагы ПУ-773 номерлы, 2017 елның 6 октябрендәге ПУ-890 номерлы, 2018 елның 20 февралендәге ПУ-187 номерлы, 2018 елның 22 июнендәге ПУ-454 номерлы һәм 2019 елның 5 июнендәге ПУ-309 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте составына керүче вазыйфаи затлар исемлегендә, «Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2019 ел, 25 сентябрь
№ ПУ-574

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ